ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“20” март 2023 ел  Калмия авылы  №5

**“2022ел өчен Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында”**

Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге халкының «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ санлы Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда һәм Тукай муниципаль районның рәсми сайтында 2022 елның 22 мартыннан да соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләргә
- үткәрү срогын – 1 көн;
- үткәрү вакытын – **2023 елның 30 мартында** 14.00 сәгатьтә;
- үткәрү урынын – Тукай районы, Калмия авылы, Яшьләр урамы, 24 йорт (Исполком бинасы);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресы – Тукай районы, Калмия авылы, Яшьләр урамы, 24 йорт (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатька кадәр);
- чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2022 елның 29 мартына кадәр.

4.Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Калмия авыл җирлеге Башлыгы  Р.Ә.Гарипов